

Козләр vтеп килә, кышка кереп барабыз. Кvпләребез vзебездән калган ризыкларны чvплеккә ташлый. Ә бит шул калдыкны кошларга да ашатырга була. Ә бит кvбебез, кvпме кош кышкы салкында жим таба алмый ачлыктан vлvләре турында уйламый да торгандыр.

Әнә шул игелекле гамәлне Ковылкино районы ГКУ РМ «Ковылкинское территориальное лесничество» урманчылыгы хезмәткәрләре кошлар очен жимлек ясап, аларны урман тирәлекләренә элгәннәр. Мәрхәмәтле кешеләр, һәр елнын октябрь ае азагында ук эленеп куелган жимлекләргә, жим салып китәләр. Шулай итеп кышларга калган кошларыбызны, безнен якын дусларыбызны, кыш салкыннарында яки урманнарда алар очен азык калмагач, ачлыктан коткаралар. Темников районындагы Петр Гермогенович Смидович исемен йорткән Мордовия заповеднигы инспекторлары да табигать һәм анда яшәvче кошлар, жәнлекләр белән һәрвакыт тыгыз бәйләнештә. Кошлар очен жимлекләр ясап, аларны урманда эләләр, урман жәнлекләренә корпә, печән азыгы куялар.
- Кышын кошлар, урман жәнлекләре аеруча кызганыч. Шуна да әлеге жан ияләренә карата бу игелекне бергәләшеп башкарсак иде. Табигатьне, әйләнә-тирә мохитне саклау, киләчәк буынга шуны ойрәтv - саваплы бурыч бит. Һәрберебез кошларга аз гына булса да олеш чыгарса, алар кышны жинелрәк уздырыр иде,- ди заповедник директоры, биология фәннәр докторы, профессор Александр Борисович Ручин.
Кышларга калган кошларыбызга гадәттән кvбрәк жим генә кирәк була салкыннарда. Табигатьнен кырыс шартларын ерып чыгуда зур рольне жимлекләр кую уйный. Елнын барлык фасылларында урманда тукранybыз тукылдап утыра, урман тавыгы кышка калган жиләкләрне, мәсәлән, можжевельник бореләрен һәм зирек алкаларын ашый, ә песнәкләребез авыл һәм шәһәр тирәләренә ук жим эзләп килә. Укучыларыбыз ясап куйган жимлекләрдә еш кына кышкы кунакларны кvрv кvнелләребезгә рәхәтлек хисе уята.
«Ин матур сыерчык оясы» дигән конкурслар республикабыз мәктәпләрендә vткәрелә. Шулай, ел саен Дубенка районы Ломат, аннары Кочкурово мәктәбендә хезмәт итәкән биология укытучысы Альфия Кеддvс кызы Узбякова, укучылары белән бергәләп, шундый конкурсларда катнаша. Быел да катнашырга жыеналар, - дип сойләде ул.
Кошлар бездән ярдәм котә; жимлекләр ясап элегез. Жимлекләр ясап кошларны сыйлау

кызыклы, бик файдалы эш ул.

**Н.Хәлил**